# Син дә татарча сөйләш!

*Әниләр бәйрәме

*Бөгелмә 6нчы урта  гомуми белем бирү мәктәбе «Мин татарча сөйләшәм!” акциясенә кушылды

*5-6нчы сыйныфлар арасында стенгазета конкурсы

* Нәүрүз бәйрәме

* Балалар иҗаты



**МАР
Т**

# Әниләр бәйрәме





*Җылы кояш нурларына төренеп, йөгерек гөрләвекләре белән йөгереп язның беренче ае — март та килеп җитте. Барыбызга да билгеле, әлеге айның иң матур, иң олы бәйрәме — 8 Март — Халыкара хатын-кызлар көне.*

**Бәйрәмнең тарихы 1857 нче елдан башлана. Ул вакытта Нью-Йорк тегүчеләре кечкенә хезмәт хакына канәгатьсезлек белдергән. Нәкъ 8 нче март көнне шәһәрдә массакүләм демонстрациягә чыгалар.Әлеге көнне рәсми төстә бәйрәм итүгә исә Германия революционеры Клара Цеткин сәбәпче. Россиядә 1965 нче елдан 8 нче март рәсми төстә ял көне. Әйтик, Үзбәкстанда ул әниләр көне булып санала. Әрмәнстанда мондый бәйрәм өчен 7 нче апрельне сайлаганнар.**





7oom.ru


# «Мин татарча сөйләшәм!» акциясе








**Үзәк балалар китапханәсе**



**Бөгелмә 6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе «Мин татарча сөйләшәм!” акциясенә кушылды**

Бөгелмә 6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбендә меңнән артык бала белем ала. Барысы да да татар телен өйрәнә. Мәктәптә үткәрелгән чараларда укучыларыбыз бик теләп катнашалар. Конкурсларны башта классларда үткәрәбез. Аннан мәктәпкүләм сайлап алу туры була.

“Мин татарча сөйләшәм!” акциясе күп санлы аудитория белән эшләргә уңайлы. Ул татар теле һәм әдәбияты укытучылары җитәкчелегендә, оешкан төстә алып барыла. Укучылар җәмәгатьчелек белән очрашуда да актив катнашалар. Бу бәйге Халыкара туган тел көненнән башланып китте. Әлеге акция кысаларында чаралар Тукай көннәре белән үрелеп, Җиңү бәйрәменә кадәр дәвам итәчәк. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары сыйныф укучылары белән урамнарда, төрле оешмаларда, кибетләрдә бөгелмәлеләр белән очрашулар үткәрделәр, шәһәрдәшләребезне татарча сөйләшергә чакырдылар, үзләре дә саф татарча әңгәмә кордылар. Бүгенге көндә “Әкиятләр иленә сәяхәт” дәресләре, класстан тыш чаралар, әңгәмәләр үткәрелә. Әйе, сөйләмебез чиста, саф, аңлаешлы, җыйнак һәм аһәңле булсын өчен укытучыларыбыз төрле эшләр башкаралар.

Әйдәгез, бергәләп татарча туган телебездә матур итеп сөйләшик, аңлашыйк, аралашыйк!






## *“Мин татарча сөйләшәм” акциясе дәвам итә.....*

**5-6нчы сыйныфлар арасында стенгазета конкурсы узды.**














# Нәүрүз бәйрәме












Гадәт буенча, Нәүрүз көнне иртә таңнан яшьләр урамга чыкканнар. Егетләр арасында бәйрәмнең башлыгы Алпамша билгеләнгән. Алпамша булган кеше: «Әнә карга очып килә, Нәүрүзне бәйрәм итәргә куша!» – дип кычкырып җибәргән. Бу бәйрәмдә милли уеннар, спорт ярышлары, атлар чабышы үткәрелгән. Нәүрүзгә кадәр кешеләр бер-берсенә булган үпкәләрен гафу иткән, дуслашу билгесе итеп, бүләкләр бирешкәннәр. Ә яшьләр кызыклы такмаклар әйтешкән. Нәүрүз бәйрәмен шулай ук «Карга туе» дип йөрткәннәр һәм бу көнне «карга боткасы» пешергәннәр. Элек кешеләр табигатьнең уянуын каргалар килү белән бәйләгән, җылы, матур көннәрне нәкъ менә шул кошлар алып килә дип уйлаганнар. Шуңа күрә карга изге кош булып саналган. Иген чәчәр алдыннан бабаларыбыз, бәйрәм ясап, күңелләрен күтәргән. Иртәннән балалар җыелышып, өйдән өйгә йөреп, ботка пешерер өчен он, ярма,йомырка, май, җимешләр җыйганнар. Аларны бер кеше дә буш кул белән чыгармый. Балалар өй янына киләләр дә, җырлап, такмаклар әйтеп әлеге өйгә, аның хуҗаларына изге теләкләр телиләр. Шулай итеп, бөтен йортка кереп чыгалар һәм җыйган әйберләрен өлкәннәргә кайтарып бирәләр. Өлкәннәр болынга чыгып ботка пешерә, ә яшьләр, балалар шунда җырлыйлар, бииләр, такмак әйтәләр, төрле кызыклы уеннар уйныйлар. Бу бәйрәмдә кешеләр ял вакытларын бик күңелле үткәрә. Соңыннан бергәләшеп ботка ашыйлар, бер-берләренә теләкләр телиләр: дөньялар имин булсын, сугышлар булмасын, яңгырлар яусын, игеннәр уңсын, балалар акыллы, тәүфыйклы, миһербанлы булсыннар. Бүгенге көндә Нәүрүз бәйрәменә багышланган «Нәүрүзбикә», «Нәүрүз гүзәле» бәйгеләрен үткәрү таралды. Ул бәйгеләрдә татар кызлары бөтен яклап үзләренең осталыгын күрсәтә. Анда алар татар халык җырларын башкаруда, милли бию осталыгында, татар халык ашларын әзерләүдә ярыша. Егетләр арасында канат тартышу, уктан ату һәм башка ярышлар үткәрелә. Татар халкында гадәттә Нәүрүзне өч көннән алып 13 көнгә хәтле билгеләп үткәннәр. Бәйрәм вакытында зур учак ягу, аның аша сикерү, өйләнү булган, кешеләр бер-берсенә бәхет, муллык теләгән.

Наил Нәбиуллин

7oom.ru



Миронов Иван,4в



Зареева Алиса, 4в



Зареева Кира, 4а

## *Халык сынамышлары*

- Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коры була.
- Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласа, яз тиз килә.
- Кара карга килгәч, бер айдан кар кар китәр.
- Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.
- Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.
- Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.
- Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.
- Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.
- Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.
- Яз көне елгаларда су артмаса,ашлык уңмас.
- Яз көне хайван аяк эзләре эресә, җылытыр.
- Черкиләр яз көне иртә күренсәләр, һава җылыныр.



Коледин Данил, 4а



Касатов Сева, 4в



Ивкина Лиза, 4в

Бөгелмә шәһәре Татарстан Республикасы
муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче
6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе

7нче В сыйныфы укучылары һәм
туган тел һәм әдәбияты укытучылары